КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 декабрь г.Казань № 1096

«Түбән Кама педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә Н.Ш.Әхмәтшин исемен бирү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башлыгы һәм «Түбән Кама педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең хезмәт коллективы советының «Түбән Кама педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә Н.Ш.Әхмәтшин исемен бирү хакындагы тәкъдимен кабул итәргә һәм алга таба аны «Н.Ш.Әхмәтшин исемендәге Түбән Кама педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе дип атарга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә «Түбән Кама педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин